ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО АЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ИБЫНДАГЫПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы,
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-92-40, факс: 2-61-50, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«27» 06 2022г.

**КАРАР**
№ 12

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы "муниципаль берәмлеге территориясендә ташландык суларны агызу (канализация) үзәкләштерелгән системасына агызуны гамәлгә ашыручы абонентлар өчен агынты сулар составы нормативларын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЭ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы «Салкын су белән тәэмин итү һәм су чыгару кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Агынты сулар составын һәм үзлекләрен тикшереп тору кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 22 маендагы 728 номерлы карары нигезендә, әйләнә-тирә мохиткә пычратучы матдәләрнең тискәре йогынтысын булдырмау максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Ютазы муниципаль районының» Урыссу шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлегенең үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу (канализация) системасына агынты суларны агызуны гамәлгә ашыручы абонентлар өчен агынты сулар составы нормативларын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Ютазы муниципаль районы «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу (канализация) системасына ташландык суларны агызу (чыгару) белән шөгыльләнүче барлык абонентларга ташландык сулар составы нормативларын

үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу ш.т.п. мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар аны игълан иткән көннән үз көченә керә, 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Н. Захаров

Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты карарына Кушымта
"27.06." 2022 ел № 12

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегенең үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу системасына (канализация) агынты суларны агызуны гамәлгә ашыручы абонентлар өчен агынты сулар составы нормативлары

| № т/б | Матдәнең (күрсәткечнең) исеме | Күрсәткечнең максималь рөхсәтителә торган дәрәҗәсе күрсәткеч һәм (яисә) (натураль пробада тулаем ) концентрациясе (мг/л) |
|---|---|---|
| 1. | Аммоний-ион | 25 |
| 2. | АПАВ | 0,2 |
| 3. | БПК3 | 300 |
| 4. | Үлчәнгән матдәләр | 300 |
| 5. | Тимер | 0,13 |
| 6. | Марганец | 0,3 |
| 7. | Нефть продуктлары | 0,1 |
| 8. | ХПК | 500 |
| 9. | Алты валентлы хром | 0,02 |
| 10. | Сульфатлар | 100 |
| 11. | Фосфатлар фосфоры | 12 |
| 12. | Хлоридлар | 300 |
| 13. | Очучан феноллар | 0,007 |